**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ТЮЛЯЧИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **с. Тюлячи** **КАРАР**

**«7» май 2024г.** **№ 58**

Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 9 декабрендәге 538 номерлы карары белән расланган «2021-2024 елларга Теләче муниципаль районында террорчылыкны һәм экстремизмны профилактикалау» муниципаль программасына үзгәрешләр кертү турында

«Террорчылыкка каршы тору турында» 2006 елның 6 мартындагы 35-ФЗ номерлы Федераль закон, 2024-2028 елга Россия Федерациясендә террорчылык идеологиясенә каршы тору комплекслы планы нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 елның 18 ноябрендәге 1103 номерлы «2014-2025 елларга Татарстан Республикасында җәмәгать тәртибен тәэмин итү һәм җинаятьчелеккә каршы тору» дәүләт программасын раслау турында» 2013 елның 16 октябрендәге 764 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән расланган 2014-2025 елларга Татарстан Республикасында терроризм һәм экстремизмны профилактикалау» дәүләт программасының «2014-2025 елларга Татарстан Республикасында җәмәгать тәртибен тәэмин итү һәм җинаятьчелеккә каршы тору» ярдәмче программасына кушымтага үзгәрешләр кертү турында» карары нигезендә, Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 9 декабрендәге 538 номерлы карары белән расланган «2021-2024 елларга Теләче муниципаль районында террорчылыкны һәм экстремизмны профилактикалау» муниципаль программасына (28.12.2021 № 322, 13.12.2022 № 271, 14.12.2023 № 197 карарлар редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Программага кушымта, «2021-2024 елларга Теләче муниципаль районында террорчылыкны һәм экстремизмны профилактикалау» программасы нәтиҗәләрен бәяләү индикаторлары һәм программа чаралары буенча финанслау» таблицасын 5.17 юлы белән тулыландырырга:

| | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 5.17. Россия Федерациясендә 2024-2028 елга террорчылык идеологиясенә каршы көрәшнең комплекслы планының 4 бүлеген исәпкә алып, Интернет челтәрендә (социаль челтәрләр, мессенджерлар) халыктан таләп ителгән террорчылыкка каршы контентны эшләү һәм тарату | МБУ «Олимп» ЯҮ | 2024-2026 еллар | Бастыру/лайк/перепост/фикер алышу/аудитория каралулары саны | - | - | - | 36 | 36 | 36 | - | - | - | Бюджет чыгымнары статьясы кысаларында | Бюджет чыгымнары статьясы кысаларында | Бюджет чыгымнары статьясы кысаларында |

2. Әлеге карар гамәлдәге законнар нигезендә үз көченә керә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең инфраструктур үсеш буенча урынбасары Ф.С. Вәлеевка йөкләргә.

Җитәкче И.Х. Хәмидуллин